МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.09.2021 г.Казань № 648

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 4 октябрендә 7946 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 17 маендагы 377 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2018 елның 17 маендагы 377 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2018 елның 17 маендагы 377
номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2021 елның 10 сентябрендәге 648
номерлы боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.89 статьясы, 28.3 статьясының 2 өлешендәге 27 пункты, 9.13 статьясы (социаль хезмәт күрсәтү объектларыннан һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәүдән читләшү өлешендә), 11.24 статьясы (оешма җитәкчесе яки халыкка автомобиль транспорты (җиңел таксидан тыш) хезмәтләрен күрсәтү һәм муниципальара элемтәдә автомобиль транспорты чараларыннан файдалану системасын оештыру өчен җаваплы булган башка вазыйфаи зат тарафыннан халыкка транспорт хезмәте күрсәтү системасына инвалидлар файдалана ала торган транспорт чараларын кертүне күздә тоткан закон таләпләрен бозу өлешендә), Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.6, 19.7 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының түбәндәге вазыйфаи затлары административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә хокуклы:

«Уңайлы мохит» региональ программасын тормышка ашыру мәсьәләләрен алып баручы министр урынбасары;

социаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен алып баручы министр урынбасары;

социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге җитәкчесе;

социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге җитәкчесе урынбасары;

социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты;

социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

тормыш эшчәнлеге чикләнгән затларны социаль интеграцияләү бүлеге җитәкчесе;

тормыш эшчәнлеге чикләнгән затларны социаль интеграцияләү бүлеге җитәкчесе урынбасары;

тормыш эшчәнлеге чикләнгән затларны социаль интеграцияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

тормыш эшчәнлеге чикләнгән затларны социаль интеграцияләү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

тормыш эшчәнлеге чикләнгән затларны социаль интеграцияләү бүлегенең әйдәп баручы белгече.